Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомбыт авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 6**

Шомбыт авылы 2019 елның 30 апреле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге Советының 2017 елның 1 июнендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Шомбыт авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Шомбыт авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында мәгълүматны тыңлап тикшергәннән соң, җирдән файдалану һәм төзелеш эшләрен җайга салу тәртибен камилләштерү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының "Шомбыт авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,2019 елның 15 апрелендә уздырылган ачык (гавами) тыңлауларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге Советының 2017 елның 1 июнендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Шомбыт авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 1 маддәнең тугызынчы абзацында "реконструкцияләүнең" сүзеннән соң ",сүтүнең" сүзе белән тулыландырырга;

1.2) 1 маддәне түбәндәге эчтәлектәге утыз дүртенче абзац белән тулыландырырга:

“капиталь төзелеш объектын сүтү – капиталь төзелеш объектын җимерү (табигать күренешләре яисә өченче затларның хокукка каршы гамәлләре нәтиҗәсендә җимерелүдән гайре), сүтеп алу һәм (яки) демонтажлау юлы белән капиталь төзелеш объектын юкка чыгару, шул исәптән аның өлешләрен дә”;

1.3) 1 маддәне түбәндәге эчтәлектәге утыз бишенче абзац белән тулыландырырга:

“индивидуаль торак төзелеше объекты – җир өстендәге катлары саны өчтән, биеклеге егерме метрдан артмаган аерым торучы бина, ул гражданнар тарафыннан мондый бинада яшәү белән бәйле көнкүреш һәм башка хаҗәтләрне канәгатьләндерү өчен аталган бүлмәләрдән һәм файдалану өчен ярдәмче урыннардан тора һәм мөстәкыйль күчемсез мөлкәт объектларына бүлү өчен аталмаган.”;

1.4) 1 маддәне түбәндәге эчтәлектәге утыз алтынчы абзац белән тулыландырырга:

“капиталь төзелеш объекты – төзелеше тәмамланмаган бина, төзелеш, корылма, объектлар (алга таба – тәгәлләнмәгән төзелеш объектлары), капиталь булмаган төзелешләрдән, корылмалардан һәм җир кишәрлеген бүленмәгән яхшыртудан гайре (түшәү, каплау һәм башкалар);”;

1.5) 1 маддәне түбәндәге эчтәлектәге утыз җиденче абзац белән тулыландырырга:

“капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар – җир белән ныклы бәйләнеше булмаган һәм конструкция сыйфатламалары аларны күчерүне һәм (яисә) демонтажлауны гамәлгә ашырырга һәм шуннан соң төп сыйфатламаларын үзгәртмичә, аталышларына зыян китермичә җыярга мөмкинлек бирә торган төзелмәләр, корылмалар (шул исәптән киосклар, лапаслар һәм башка шундый төзелмәләр, корылмалар)”;

1.6) 1 маддәне түбәндәге эчтәлектәге утыз сигезенче абзац белән тулыландырырга:

“Шәһәр төзелеше эшчәнлеге – территорияләрне, шул исәптән шәһәрләрне һәм башка җирлекләрне үстерү буенча территориаль планлаштыру, шәһәр төзелешен зоналаштыру, территорияне планировкалау, архитектура-төзелеш проектлавы, төзелеш, капиталь ремонтлау, реконструкцияләү, капиталь төзелеш объектларын сүтү, биналарны, корылмаларны эксплуатацияләү, территорияләрне төзекләндерү рәвешендә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек”;

1.7) 1 маддәне түбәндәге эчтәлектәге утыз тугызынчы абзац белән тулыландырырга:

“төзелеш – биналар, төзелмәләр, корылмалар булдыру (шул исәптән сүтелә торган капиталь төзелеш объектлары урынында);”.

1.8) 1 маддәнең унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Төзүче (йортлар салучы) – үзенә караган җир кишәрлегендә яисә хокук иясенең җир кишәрлегендә капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны, сүтүне, шулай ук инженерлык эзләнүләрен башкаруны, аларны төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау

өчен проект документациясен әзерләүне тәэмин итүче физик яисә юридик зат (дәүләт (муниципаль) милкендәге капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), яисә җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән очракларда килешүләр нигезендә үзләренең дәүләт (муниципаль) заказчысы вәкаләтләрен аңа тапшырганнар). Төзүче шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарда каралган үз функцияләрен техник заказчыга тапшырырга хокуклы”.

1.9) 1 маддәнең унөченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Территорияләрне файдалануның аерым шартлары булган зоналар – саклау, санитар-саклау зоналары, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) саклау зоналары (алга таба – мәдәни мирас объектлары), мәдәни мирас объектларының саклау зоналары, су саклау зоналары, су басу, су астында калу зоналары, эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналары, саклана торган объектлар зоналары, аэродром яны территориясе, Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган башка зоналар”;

1.10) 1 маддәнең унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Кызыл сызыклар – гомуми файдаланудагы территорияләрнең гамәлдәге, планлаштырыла (үзгәрә, яңа барлыкка килә) торган чикләрен һәм (яисә) линияле объектлар булган һәм (яки) линияле объектларны урнаштыруга аталган территорияләр чикләрен билгели торган сызыклар”;

1.11) 1 маддәнең кырыгынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Шәһәр төзелеше эшчәнлеге – территорияләрне, шул исәптән шәһәрләрне һәм башка җирлекләрне үстерү буенча территориаль планлаштыру, шәһәр төзелешен зоналаштыру, территорияне планировкалау, архитектура-төзелеш проектлавы, төзелеш, капиталь ремонтлау, реконструкцияләү, капиталь төзелеш объектларын сүтү, биналарны, корылмаларны эксплуатацияләү, территорияләрне төзекләндерү рәвешендә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек”;

1.12) 1 маддәнең кырык беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Техник заказ бирүче – профессиональ нигездә эш итүче физик зат яки төзүче тарафыннан вәкаләт бирелгән юридик зат, төзүче исеменнән инженерлык эзләнүләрен башкару турында, проект документациясе әзерләү турында, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау турында шартнамәләр төзи, күрсәтелгән эш төрләрен үтәүгә заданиеләр әзерли, инженерлык эзләнүләрен башкаручы һәм (яки) проект документациясен әзерләүне гамәлгә ашыручы, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлауны башкаручы затларга күрсәтелгән эш төрләрен үтәү өчен материаллар һәм документлар бирә, проект документациясен раслый, капиталь төзелеш объектларын кулланылышка кертүгә рөхсәт алу өчен кирәкле документларны имзалый, әлеге Кодекста күздә тотылган башка функцияләрне гамәлгә ашыра (алга таба шулай ук – техник заказ бирүче функцияләре). Техник заказчы функцияләрен бары тик инженерлык эзләнүләре, архитектура-төзелеш

проектлау, төзелеш, реконструкция, капиталь ремонт, капиталь төзелеш объектларын сүтү өлкәсендә үз-үзен көйләүче оешма әгъзасы гына башкара ала, моңа Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очраклар керми";

1.13) 1 маддәнең кырык икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Шәһәр төзелешен проектлау нормативлары – кешенең, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр халкының көн итү эшчәнлегенә уңай шартлар тәэмин итү максатларында РФ ШтКның 29.2 маддәсенең 1, 3 һәм 4 4 өлешләрендә күздә тотылган объектлар белән тәэмин ителешнең мөмкин булган минималь дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре һәм мондый объектларның Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр халкы өчен максималь мөмкин булган территория дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре җыелмасы;

1.14) 1 маддәнең кырык өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Җирлекнең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы – җирлекнең җирле әһәмияттәге транспорт инфраструктурасы объектларын проектлау, төзү, реконструкцияләү буенча, шулай ук дәүләт һәм муниципаль программаларында, муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясендә һәм муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планында (әлеге стратегия һәм план булганда), муниципаль берәмлекнең комплекслы социаль-икътисади үсеше планында һәм программасында, транспорт өлкәсендә табигый монополияләр субъектларының инвестиция программаларында каралган чаралар исемлеген билгели торган документ".

1.15) 1 маддәнең кырык дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Җирлекнең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы – җирлекнең җирле әһәмияттәге социаль инфраструктура объектларын проектлау, төзү, реконструкцияләү чаралары исемлеген билгели торган документ, алар шулай ук дәүләт һәм муниципаль программаларда, муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясендә һәм муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планында (әлеге стратегия һәм план булган очракта), муниципаль берәмлекнең комплекслы социаль-икътисади үсеше планында һәм программасында каралган. Җирлекнең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программалары федераль законнарда, җирлекнең генераль планнарында билгеләнгән тәртиптә расланган тәртиптә җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнә һәм раслана һәм җирле әһәмияттәге социаль инфраструктура объектлары төзелешенә ихтыяҗлар нигезендә җирлекнең социаль инфраструктурасын баланслы, перспективалы үстерүне тәэмин итәргә тиеш".

1.16) 1 маддәнең кырык бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Машина-урын (машиналарны кую урыннары) – бинаның яисә корылманың бары тик транспорт чарасын урнаштыру өчен аталган, төзелеш яисә башка киртәләү конструкциясе белән чикләнмәгән яисә өлешчә чикләнгән һәм чикләре дәүләт кадастр исәбенә алу турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә тасвирланган индивидуаль-билгеләнгән өлеше”;

1.17) 1 маддәнең кырык алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Смета нормалары – төзелешнең смета бәясен билгеләгәндә кулланыла торган материалларның, эшләнмәләрнең, конструкцияләрнең һәм җиһазларның, төзелештәге хезмәткәрләрнең хезмәт сарыф итүләре, машиналарны һәм механизмнарны эксплуатацияләү вакытының (алга таба – төзелеш ресурслары) һәм башка сарыф итүләрнең (кабул ителгән үлчәү берәмлегенә билгеләнгән) микъдар күрсәткечләре җыелмасы”;

1.18) 1 маддәнең кырык җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Төзелеш ресурсларының смета бәяләре – төзелеш ресурсларының бәясе турында территориаль кисештә документлаштырылган, кабул ителгән үлчәү берәмлегенә исәп-хисап юлы белән билгеләнгән һәм төзелештәге бәяләр ясалуның федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла торган берләштерелгән җыелма мәгълүмат”;

1.19) 1 маддәнең кырык сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Смета нормативлары – төзелешнең смета бәясен, инженерлык эзләнүләре һәм проект документларын әзерләү буенча эшләрнең, шулай ук смета нормаларын эшләү һәм куллану методикалары бәясен билгеләү өчен кирәкле смета нормалары һәм методикалары”;

1.20) 1 маддәнең кырык тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү буенча эшчәнлек – территориядән нәтиҗәлерәк файдалануны тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла торган торак, җитештерү, иҗтимагый-эшлекле һәм башка билгеләнештәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру өчен территорияне планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау эшчәнлеге, мондый объектларның эшләве һәм гражданнарның көн итү эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектларын, шулай ук әлеге пунктта күрсәтелгән объектларны архитектура-төзелеш проектлау, төзү, реконструкцияләү буенча документлар әзерләү һәм раслау эшчәнлеге”;

1.21) 1 маддәнең егерме дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“гомуми файдаланудагы территорияләр – чикләнмәгән затлар даирәсе тоткарлыксыз файдалана торган территорияләр (шул исәптән мәйданнар, урамнар, проездлар, яр буйлары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буе полосалары, скверлар, бульварлар)”;

1.22) Кагыйдәләрнең 4 маддәсенең 6 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 4 пунктны өстәргә:
“Территориянең коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителешенең мөмкин булган минималь дәрәҗәсенең исәп күрсәткечләре һәм, шәһәр төзелеше регламенты билгеләнә торган территория зонасы чикләрендә территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру каралган очракта, күрсәтелгән объектларның халык өчен территориаль файдалана алу мөмкинлегенең максималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәп күрсәткечләре”.

1.23) 4 маддәне түбәндәге эчтәлектәге 13 өлеш белән тулыландырырга:
“Шәһәр төзелеше регламентларының көче (йогынтысы, тәэсире) кагылмый (таралмый) торган яисә алар өчен шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнмәгән җир кишәрлекләреннән файдалану федераль законнар нигезендә башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органнары, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары яки җирле үзидарәнең вәкаләтле органнары тарафыннан билгеләнә. Махсус сакланылучы табигать территорияләре чикләрендә урнашкан урман фонды җирләреннән яисә җир кишәрлекләреннән файдалану урман законнары, махсус сакланылучы табигать территорияләре турындагы законнар нигезендә тиңдәшле урман хуҗалыгы регламенты, махсус сакланылучы табигать территориясе турындагы нигезләмә белән билгеләнә.”;

1.24) 9 маддәнең 1 өлеше 3 абзацындагы “шул исәптән сатып алу юлы белән” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.25) 9 маддәнең 6 абзацындагы “, капиталь ремонтның” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.26) 9 маддәне түбәндәге эчтәлектәге җиденче абзац белән тулыландырырга:
“җирлек территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрендә шәхси торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда хәбәрнамәләр җибәрү;”;

1.27) 9 маддәне түбәндәге эчтәлектәге сигезенче абзац белән тулыландырырга:
“үз белдегең белән төзелгән корылманы сүтү йә рөхсәтсез төзелгән корылманы җимерү яисә аны рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларына туры китерү, җирдән файдалану һәм төзелеш алып баруның билгеләнгән кагыйдәләре, территорияне планлаштыру буенча документация белән капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү турында карар кабул итү яисә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләр белән, гражданлык законнарында күздә тотылган очракларда рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтүне гамәлгә ашыру яки аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерү.”;

1.28) 14 маддәнең 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Кулланунын шартлы рөхсәт ителгән планына рөхсәт бирү турында карар проекты, РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезләмәләрен исәпкә алып, әлеге Кагыйдәләрнең 30.1 маддәсендә билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган җәмәгатьчелек фикер алышуларында яисә ачык (гавами) тыңлауларда каралырга тиеш. Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдаланунын рөхсәт ителгән планы әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясарга мөмкин булган очракта, җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының мондый тискәре йогынтылы куркыныч астына куйган хокук ияләре катнашында уздырыла”;

1.29) 14 маддәнең 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Җәмәгатьчелек фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны оештыручы әлеге рөхсәт соратыла торган җир кишәрлеге белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләренең хокукый ияләренә, әлеге рөхсәт соратыла торган җир кишәрлеге белән гомуми чикләре булган җир кишәрлекләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокукый ияләренә һәм әлеге рөхсәт соратыла торган капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган биналарның хокукый ияләренә шартлы рәвештә файдалану планына рөхсәт бирү турында карар проекты буенча җәмәгатьчелек фикер алышулары яки гавами тыңлаулар уздыру хакында хәбәрләр җибәрә. Күрсәтелгән хәбәрләр кызыксынган затның файдаланунын шартлы рөхсәт ителгән планына рөхсәт бирү турында гаризасы алынган көннән соң ун көннән дә соңга калмыйча җибәрелә”;

1.30) 14 маддәнең 5,6 өлешләрен көчен югалткан дип танырга;

1.31) 14 маддәнең 7 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Шомбыт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге халкына җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә игълан ителгән көнгә кадәр аларны уздыру турында хәбәр иткән көннән алып җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә ачык тыңлаулар үткәрү чоры (срогы) “Шомбыт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең Анатыш авыл җирлеге Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан артык була алмый.”

1.32) 14 маддәнең 8 пунктында “ачык тыңлаулар нәтиҗәләре” сүзләрен “җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә” сүзләре белән алмаштырырга.

1.33) 14 маддәнең 10 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Файдаланунын шартлы рөхсәт ителгән планына рөхсәт бирү турында карар проекты буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларын яки гавами тыңлауларын оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны мондый рөхсәтне бирү белән кызыксынган физик яки юридик зат үз өстенә ала”;

1.34) 14 маддәнең 11 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Капиталь төзелеш объектының җир участогыннан яисә объектыннан файдаланунын шартлы рөхсәт ителгән планы җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә җәмәгатьчелек фикер алышуларыннан яки физик яки юридик зат инициативасы буенча гавами тыңлаулар үткәргәннән соң

үзгәрешләр кертү өчен билгеләнгән шәһәр төзелеше регламентына кертелгән очракта, мондый затка файдалануның шартлы рөхсәт ителгән планына рөхсәт бирү турындагы карар җәмәгатьчелек фикер алышуларыннан яки гавами тыңлаулардан башка кабул ителә”;

1.35) 14 маддәне түбәндәге эчтәлектәге 11.1 өлеш белән тулыландырырга:

“Җирле үзидарә органына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.32 маддәсенең 2 өлешендә күрсәтелгән дәүләт хакимиятенең башкарма органыннан, вазифаи заттан, дәүләт учреждениесеннән яисә җирле үзидарә органыннан үз белдеге белән төзелгән корылма беленү турында хәбәрнамә килеп ирешкән көннән башлап андый корылма урнашкан җир кишәрлегенә карата яисә мондый төзелешкә карата аны сүткәнче яисә билгеләнгән таләпләргә туры китергәнче шартлы рөхсәт бирү рөхсәт ителми, әлеге хәбәрнамәне җирле үзидарә органы тарафыннан карау нәтиҗәләре буенча РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55.32 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән дәүләт хакимиятенең башкарма органына, вазифаи затка, дәүләт учреждениесенә яки җирле үзидарә органына һәм әлеге хәбәрнамә килеп ирешкән, үз белдегең белән төзелгән билгеләрнең булуы күренми яисә судның үз белдегең белән корылманы сүтү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турындагы дәгъва таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тарту турындагы карары закон көченә керүе турында хәбәр җибәрелгән очраклардан гайре “.

1.36) 16 маддәнең 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Шомбыт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының әлеге кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турында карар проекты, территорияне планлаштыру проектлары һәм территорияне планлаштыру буенча документлар составында әзерләнгән территорияне ызанлау проектлары,
җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлы рөхсәт ителгән планына рөхсәт бирү, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү мәсьәләләре җәмәгатьчелек фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда РФ ШтКның 5.1 маддәсендә билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турында карар проекты буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларын яки гавами тыңлауларын оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны мондый рөхсәтне бирү белән кызыксынган физик яки юридик зат үз өстенә ала”;

1.37) 16 маддәнең 2 өлешен “уздыруның” сүзеннән соң “җәмәгатьчелек фикер алышулары яки” сүзләре белән тулыландырырга;

1.38) Кагыйдәләрнең 20 маддәсенең 6 өлешендә “шул исәптән сатып алу юлы белән” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.39) 25 маддәнең 2 өлешендә “гараж төзелешенең” сүзләрен “гараж төзелешенең, реконструкцияләүнең” сүзләренә алмаштырырга, “бакчачылык, дача хуҗалыгы алып бару өчен бирелгән җир кишәрлегендә төзелешнең” сүзләрен “бакча җир кишәрлегендә торак йорт, бакча йорты, хуҗалык корылмалары төзү, реконструкцияләүнең” сүзләренә алмаштырырга;

1.40) 25 маддәне түбәндәге эчтәлектәге 2.1) пункты белән тулыландырырга:

“2.1) индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү, реконструкцияләү;”

1.41) 26 мадданең 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Проект документларын әзерләү төзүче яисә заказчы биреме нигезендә гамәлгә ашырыла (проект документациясен үтәүче тарафыннан шартнамә нигезендә әзерләгәндә). Проект документларын әзерләү, шулай ук мондый проект документациясе нигезендә капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү тиешле инженерлык эзләнүләрен башкармыйча рөхсәт ителми”;

1.42) 26 мадданең 6 өлешендәге 4 абзацта “шартнамәнең” сүзеннән соң “проект документациясен әзерләүгә подрядның” сүзләре белән тулыландырырга;

1.43) Кагыйдәләрнең 26 маддәсенең 7 өлешендәге 7 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Муниципаль милектәге җир кишәрлекләре белән эш итүгә вәкаләтле җирле үзидарә органы аукцион уздыру көненә кадәр утыз көннән дә соңга калмыйча йә муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү турында карар кабул ителгән көнгә кадәр йә мондый җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән көнгә кадәр әлеге җир кишәрлеген тоташтыруның (технологик ялгауның) техник шартларын кызыксынучы затларга инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруның (технологик ялгауның) техник шартларын, капиталь төзелеш объектын инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик ялгау) срогын, техник шартларның гамәлдә булу срогын һәм тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү турында мәгълүмат бирә. Җир кишәрлекләре белән эш итүгә вәкаләтле авыл җирлеге башкарма комитеты муниципаль милектә булган җир кишәрлеген сату буенча аукцион үткәрү яки мондый җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион үткәрү турында гариза кергән көннән ундүрт көн эчендә мондый җир участогын инженер-техник тәэмин итү челтәрләреннән файдалануга тапшыручы оешмаларга әлеге техник шартлар, аларның гамәлдә булу вакыты һәм технологик тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү турында мәгълүмат бирү турында гарызнамә җибәрә)”;

1.44) 26 мадданең 2 пунктындагы 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 маддәсенең 13 өлешендә каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, капиталь төзелеш объектларының проект документлары составына түбәндәге бүлекләр кертелә:

- беренчел мәгълүматлар белән аңлатма язуы, шул исәптән инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруның (технологик ялгауның) техник шартлары белән, һәм инженер эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза үткәрелгән очракта, проект документациясенә экспертиза уздырганчыга кадәр, инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә уңай экспертиза нәтиҗәләре реквизитлары белән;

- җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган җир кишәрлеген планлаштыру схемасы, ә линияле объектларга карата проект документациясен әзерләгән очракта, территорияне планлаштыру проекты нигезендә башкарылган бүлү полосасы проекты (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан гайре);

- архитектура, функциональ-технологик, конструктив, инженер-техник чишелешләр һәм (яисә) түбәндәгеләрне үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар булган бүлекләр:

а) техник регламентлар таләпләрен, шул исәптән механик, янгын һәм башка иминлек таләпләрен, энергетика нәтиҗәлелеге таләпләре, биналарга, төзелмәләргә һәм корылмаларга карата кулланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән биналарның, төзелмәләр һәм корылмаларның җиһазланышы таләпләрен (шул исәптән алар составына керүче инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә һәм системаларына), инвалидларның капиталь төзелеш объектына керү-үтү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен (сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт һәм башка социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, торак фонды объектларына карата проект документациясен әзерләү очрагында);

б) санитар-эпидемиологик таләпләр, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге таләпләр, атом энергиясен имин куллануга таләпләр, сәнәгать иминлеге таләпләре, электр энергетикасы системаларының һәм электр энергетикасы объектларының ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүгә таләпләр, объектларның террорчылыкка каршы саклануы таләпләрен;

в) биналарны һәм корылмаларны проектлау, төзү, монтажлау, көйләү, эксплуатацияләү процессларына таләпләрне;

г) капиталь төзелеш объектларын инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруның (технологик ялгауның) техник шартлары таләпләрен;

- капиталь төзелеш объектларын төзүне оештыру проекты;

- капиталь төзелеш объектларыннан имин файдалануны тәэмин итүгә таләпләр;

- капиталь төзелеш объектын куркынычсыз эксплуатацияләүне тәэмин итү өчен кирәкле капиталь ремонт буенча эшләрне башкаруның норматив периодиклыгы турында мәгълүматлар, шулай ук күпфатирлы йортны төзү, реконструкцияләү өчен проект документациясен әзерләгәндә күрсәтелгән эшләрнең күләме һәм составы турында мәгълүматлар.”;

1.45) 26 маддәнең 8 өлешен түбәндәге эчтәлектәге 6.1 пункты белән тулыландырырга:

“Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында”гы Федераль законда каралган очракларда юл хәрәкәтен оештыру проекты”;

1.46) 26 маддәнең 8 өлеше 7 пунктында “яки демонтажлауга” һәм “яки демонтажлауның” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.47) Кагыйдәләрнең 26 маддәсенең 8 өлеше 9 пунктында “тиңдәшле” сүзен төшереп калдырырга, “документациянең” сүзеннән соң “мондый объектларны төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау өчен)” сүзләре белән тулыландырырга;

1.48) 26 маддәнең 8 өлеше 15 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Проект документациясе экспертизасына һәм дәүләт төзелеш күзәтчелеге органнарына тапшырыла торган проект документларының составы һәм бүлекләре эчтәлегенә карата таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә һәм капиталь төзелеш объектларының төрле төрләренә карата дифференциацияләнә (шул исәптән линияле объектларга карата да), шулай ук капиталь төзелеш объектларының билгеләнешенә, эш төрләренә бәйле рәвештә (капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау), аларның эчтәлеге, эшләрне финанслау чыганаклары һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 маддәсе таләпләре нигезендә төзелешнең, реконструкциянең аерым этапларын бүлү һәм түбәндәге үзенчәлекләрне исәпкә алып:

- капиталь төзелеш объектларының төрле төрләренә карата аерым бүлекләр күләмендә проект документациясен әзерләү гамәлгә ашырыла (шул исәптән линияле объектларга), шулай ук капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләгәндә башкарыла торган эшләр эчтәлегенә бәйле рәвештә проектлауга төзүче яисә техник заказчы биреме нигезендә (капиталь төзелеш объектын реконструкцияләү үткәрелгән очракта);

- капиталь төзелеш объектларын төзүне оештыру проектында капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү эшләрен оештыру проекты булырга тиеш (капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен капиталь төзелешнең башка объектларын төзү, реконструкцияләү өчен сүтү кирәк булган очракта);

- проект документациясендә булган карарлар һәм чаралар мәдәни мирас объектларын саклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килергә тиеш (мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләр башкару өчен проект документациясен әзерләгәндә мондый объектларның конструкция һәм башка ышанычлылык һәм куркынычсызлыгы сыйфатламасына кагыла торган очрак булса);

- проект документациясе "Капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә, капиталь ремонтлауга, сүтүгә смета" бүлеген үз эченә алырга тиеш (төзелеш, реконструкцияләү, сүтү Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты акчаларын, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8.3 маддәсенең 2 өлешендә күрсәтелгән юридик затлар акчаларын җәлеп итеп, капиталь ремонт Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты акчаларын, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8.3 маддәсенең 1 өлешендә күрсәтелгән затлар акчаларын җәлеп итеп финанслана торган очракларда);

- “Хәтәр производство объектларының сәнәгать иминлеге турында” 1997 елның 21 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсенең 3 пунктында, “Гидротехник корылмаларның иминлеге турында” 1997 елның 21 июлендәге 117-ФЗ номерлы Федераль законның 10 маддәсендә, “Атом энергиясен файдалану турында” 1995 елның 21 ноябрендәге 170-ФЗ номерлы Федераль законның 30 маддәсендә, “Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында” 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның 36 маддәсенең 2 һәм 3 пунктларында каралган очракларда проект документациясе составына мәҗбүри тәртиптә күрсәтелгән федераль законнарда каралган документация, проект документациясе бүлекләре кертелә.”;

1.49) 26 маддәнең 8 өлеше 10 пунктында “капиталь ремонт” сүзләреннән соң “,сүтү” сүзен өстәргә;

1.50) 26 маддәнең 1 пунктында 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыру индивидуаль торак төзелеше объектын, бакча йортын төзегәндә, реконструкцияләгәндә таләп ителми. Төзүче үз инициативасы белән индивидуаль торак төзелеше объектына, бакча йортына карата проект документациясен әзерләүне тәэмин итәргә хокуклы.”;

1.51) 26 маддәнең 8 өлешен түбәндәге эчтәлектәге 11.1 пункты белән тулыландырырга:

“Мондый йорттан имин файдалануны тәэмин итү өчен кирәкле күпфатирлы йортка капиталь ремонт ясау буенча эшләрне башкаруның норматив периодиклылыгы турында, күрсәтелгән эшләрнең күләме һәм составы хакында мәгълүматлар (күпфатирлы йортны төзү, реконструкцияләү өчен проект документациясен әзерләгән очракта)”;

1.52) Кагыйдәләрнең 26 маддәсенең 10 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Проект документлары төзүче, техник заказчы, бинаны, корылманы эксплуатацияләү өчен җаваплы зат яисә төбәк операторы тарафыннан раслана. РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсендә каралган очракларда төзүче яки техник заказчы проект документациясе расланганчыга кадәр аны экспертизага җибәрә. Шул ук вакытта проект документлары төзүче яисә техник заказчы тарафыннан проект документларына уңай экспертиза бәяләмәсе булганда раслана”;

1.53) 27 маддәнең 5 өлешендә 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре һәм проект документларындагы түбәндәге материаллар:

- аңлатма язуы;

- җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган җир кишәрлеге планлаштыру схемасы, ә линияле объектларга карата проект документациясен әзерләгән очракта, территорияне планлаштыру проекты нигезендә башкарылган бүлү полосасы проекты

(линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан гайре);

- архитектура һәм конструктив чишелешләр булган бүлекләр, шулай ук инвалидларның капиталь төзелеш объектына керә алуын тәэмин итүгә юнәлдерелгән карарлар һәм чаралар (сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт һәм башка социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать тукланыуы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, торак фонды объектларына карата проект документациясен әзерләү очрагында);

- капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты (башка төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү өчен капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү кирәк булу очрагында капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү буенча эшләрне оештыру проектын да кертеп);”;

1.54) 27 маддәнең 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә экспертиза нәтиҗәсе булып инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренең техник регламентлар таләпләренә туры килүе (уңай бәяләмә) яисә туры килмәве (тискәре бәяләмә) турындагы бәяләмә тора. Проект документациясенә экспертиза нәтиҗәсе булып түбәндәге бәяләмә тора:

- проект документациясенең инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә, проектлау биременә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5 өлешендәге 1 пунктында каралган таләпләргә туры килүе (уңай бәяләмә) яисә туры килмәве (тискәре бәяләмә) турында (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49.3 маддәсендәге 3.3 өлешенең 1 пункты нигезендә проект документациясенә экспертиза уздыру очракларыннан гайре);

- Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8.3 маддәсендәге 2 өлешендә билгеләнгән очракларда капиталь төзелеш объектлары төзелешенең смета бәясен билгеләүнең дөреслеге (уңай бәяләмә) яисә дөрес булмавы (тискәре бәяләмә) турында.”;

1.55) 27 маддәнең 6 өлеше 1 пунктында “җир кишәрлегенә” сүзләреннән соң “шул исәптән сервитут билгеләү турында килешү, ачык сервитут билгеләү турында карар” сүзләре белән тулыландырырга;

1.56) 27 маддәнең 6 өлешен түбәндәге эчтәлектәге 1.1 пункты белән тулыландырырга:

“Дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), "Росатом" атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, "Роскосмос" космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджеттан тыш фонды белән идарә итү органы яки җирле үзидарә органы тарафыннан дәүләт (муниципаль) заказчысы вәкаләтләрен тапшыру турында Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән очракларда бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда төзелгән килешү булганда, - әлеге килешү төзелгән хокук иясенең җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар”;

1.57) 27 мадданең 6 өлешендә 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Төзелешкә рөхсәт алу өчен гариза биргән көнгә кадәр өч елдан да иртәрәк бирелмәгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы яки линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты реквизитлары (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан гайре), урнаштыру өчен җир кишәрлеге төзү таләп ителми торган линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта территорияне планлаштыру проекты реквизитлары ".

1.58) 27 мадданең 5 өлешендә 6 пунктны “,әлеге өлешнең 6.2 пунктында күрсәтелгән күпфатирлы йортны реконструкцияләү очракларыннан гайре” сүзләре белән тулыландырырга;

1.59) 27 мадданең 5 өлешен түбәндәге эчтәлектәге 6.1 пункты белән тулыландырырга:

“Дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, "Росатом" дәүләт корпорациясе, "Роскосмос" космик эшчәнлеге буенча дәүләт корпорациясе, бюджеттан тыш дәүләт фонды идарәсе органы яки җирле үзидарә органы булган дәүләт заказчысы реконструкция үткәргән очракта, хокукый иясе булып дәүләт (муниципаль) унитар предприятиесе, дәүләт (муниципаль) бюджет яисә автоном учреждениесе торган дәүләт (муниципаль) милкендәге капиталь төзелеш объектында аңа карата күрсәтелгән орган тиңдәшле рәвештә оештыручы вәкаләтләрен дә яисә мөлкәт милекчесе функцияләрен дә гамәлгә ашыра – мондый реконструкция үткәрү турында килешү, шул исәптән реконструкцияне гамәлгә ашырганда күрсәтелгән объектка китерелгән зыянны каплау шартларын һәм тәртибен билгели”;

1.60) 27 мадданең 5 өлешен түбәндәге эчтәлектәге 6.2 пункты белән тулыландырырга:

“күпфатирлы йортны реконструкцияләгән очракта торак законнары нигезендә кабул ителгән күпфатирлы йорттагы урыннар (бүлмәләр) һәм машина-урын милекчеләренең гомуми җыелышы карары, яисә әгәр мондый реконструкция нәтиҗәсендә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәт күләме кимесә, күпфатирлы йорттагы барлык урыннар (бүлмәләр) һәм машина-урын милекчеләренең ризалыгы”;

1.61) 27 мадданең 7 пунктын түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга:

“Әлеге мадданең 6 пунктында күрсәтелгән документларны төзүгә рөхсәтнамә бирүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнарына, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнары һәм оешмаларга электрон рәвештә җибәрү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.”;

1.62) 27 мадданең 8 пунктындагы 3 абзацта “яки индивидуаль торак төзелеше объектын урнаштыру урынын билгеләп, җир кишәрлеген

планлаштыру схемасы” сүзләрен һәм “яисә җир кишәрлегенең күрсәтелгән планлаштыру схемасын” төшереп калдырырга;

1.63) 27 маддәнең 8 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Төзелешкә рөхсәт бирү буенча вәкаләтле җирле үзидарә органы төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза алган көннән алып җиде эш көне эчендә, РФ ШтК ның 51 маддәсенең 11.1 өлешендә каралган очрактан гайре:

1.төзелешкә рөхсәт бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле документларның булу-булмавын тикшерә;

2. проект документациясенең капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә карата тапшырылган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын төзүгә рөхсәт алу өчен бирелгән датага билгеләнгән таләпләргә яисә, линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты таләпләренә, урнаштыру өчен җир кишәрлеге төзү таләп ителми торган линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта территорияне планлаштыру проектында билгеләнгән таләпләргә туры килүен, шулай ук капиталь төзелеш объектын җир кишәрлегеннән файдалану рөхсәт ителгән файдалану һәм Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләүләр нигезендә урнаштыруның мөмкинлеген тикшерә (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру документларын әзерләү таләп ителмәгән очраклардан гайре). Рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкциянең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирелгән очракта, проект документларының рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкциянең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерү үткәрелә;

3. төзелешкә рөхсәт бирә яисә, кире кагуның сәбәпләрен күрсәтеп, мондый рөхсәт бирүдән баш тарта.”;

1.64) Кагыйдәләрне түбәндәге эчтәлектәге 27.1 маддәсе белән тулыландырырга:

“ 27.1. маддә. Шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яисә реконструкцияләү турында хәбәрнамә.

Индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яисә реконструкцияләү максатларында төзүче кәгазь йөрткечтә төзүгә рөхсәт бирүгә вәкаләтле җирле үзидарә органына, шул исәптән күпфункцияле үзәк аша шәхсән мөрәҗәгать итү юлы белән, йә күрсәтелгән органнарга почта аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталыннан индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын планлаштырыла торган төзү яки реконструкцияләү турында түбәндәге мәгълүматлары булган хәбәрнамә (алга таба – планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә) җибәрә:

- төзүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны, шәхесне таныклаучы документ реквизитлары (физик зат өчен);

- төзүченең исеме һәм урнашу урыны (юридик зат өчен), шулай ук юридик затларның бердәм дәүләт реестрында юридик затны дәүләт теркәве турында

язманың дәүләт теркәү номеры һәм салым түләүченең таныклау номеры (ИНН), мөрәҗәгать итүче чит ил юридик заты булган очрактан гайре;
- җир кишәрлегенең кадастр номеры (ул булган очракта), җир кишәрлегенең адресы яисә урынының тасвирламасы;
- төзүченең җир кишәрлегенә хокукы турында мәгълүматлар, шулай ук җир кишәрлегенә башка затларның хокуклары булу турында мәгълүматлар (мондый затлар булганда);
- җир кишәрлегеннән һәм капиталь төзелеш объектыннан рөхсәт ителгән файдалану рәвеше турында мәгълүматлар (индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының);
- планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә бирелгән индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының яисә бакча йортының планлаштырыла торган параметрлары турында мәгълүматлар, шул исәптән җир кишәрлеге чикләреннән чигенүләр турында;
- индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының мөстәкыйль күчемсез мөлкәт объектларына бүлү өчен аталмавы турында мәгълүматлар;
- йорт салучы (төзүче) белән элемтә өчен почта адресы һәм (яисә) электрон почта адресы;
- төзүчегә әлеге матдәнең 7 өлешендәге 2 пунктында һәм 8 өлешендәге 3 пунктында каралган хәбәрнамәләрне юллау ысулы.
Планлаштырылган төзелеш турында хәбәрнамәгә кушымта итеп бирелә:
- җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар, әгәр аңа хокуклар күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса;
- планлаштырылган төзелеш турында хәбәрнамә төзүче вәкиле тарафыннан җибәрелгән очракта төзүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ;
- төзүче чит ил юридик заты булган очракта чит ил дәүләте законнары нигезендә юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы документларның рус теленә таныкланган тәрҗемәсе;
- шәхси торак төзелеше яки бакча йортының тышкы кыяфәтенең тасвирламасы, әгәр дә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырыла икән, әлеге матдәнең 5 өлешендә каралган очрактан гайре. Шәхси торак төзелеше яисә бакча йортының тышкы кыяфәтен тасвирлау текст рәвешендәге тасвирламаны һәм график тасвирламаны үз эченә ала.
Индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йортының тышкы кыяфәтен тасвирлау текст рәвешендә индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларын күрсәтүне, аларның тышкы кыяфәтен төс ягыннан хәл итүне, индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йортының тышкы кыяфәтен билгеләүче төзелеш материалларын үз эченә ала, шулай ук шәһәр төзелеше регламентында капиталь төзелеш объектының архитектур чишелешләренә карата таләпләр буларак билгеләнгән индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының башка сыйфатламаларын тасвирлауны. График тасвирлама индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йортының тышкы

кыяфәте, шул исәптән индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының фасадын һәм конфигурациясен сурәтләүне тәшкил итә.

1.Әлеге мадднең 3 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган мәгълүматлар) әлеге мадднең 1 өлешенең беренче абзацында күрсәтелгән органнар тарафыннан әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм дәүләт органнарыннан яки җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалардан, әгәр төзүче үзе күрсәтелгән документларны мөстәкыйль рәвештә тапшырмаса, планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә алган көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча соратып алына. Әлеге мадднең 1 өлешенең беренче абзацында күрсәтелгән органнарның ведомствоара гарызнамәләре буенча әлеге мадднең 3 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яисә алардагы мәгълүматлар) дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалар тарафыннан шушы документлары булган оешмалар карамагында тиешле ведомствоара гарызнамәне алган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча бирелә. Төзүче (йорт салучы) әлеге тарихи җирлек өчен “Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында” 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә расланган капиталь төзелеш объектының үрнәк архитектура чишелеше нигезендә федераль яисә региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектын төзүне яисә реконструкцияләүне гамәлгә ашырырга хокуклы. Бу очракта планлаштырылган төзелеш турында хәбәрнамәдә шундый үрнәк архитектура чишелешенә күрсәтелә (игътибар юнәлтелә). Планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йортының тышкы кыяфәтен тасвирлау кушымтасы таләп ителми.

2.Планлаштырылучы төзелеш турында хәбәрнамәдә әлеге мадднең 1 өлешендә каралган мәгълүматлар яисә әлеге мадднең 3 өлешенең 2 - 4 пунктларында каралган документлар булмаган очракта, төзелешкә рөхсәтләр бирүгә вәкаләтле орган һәм җирле үзидарә органы, планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә кергән көннән алып, өч эш көне эчендә төзүчегә әлеге хәбәрнамәне һәм аңа кушып бирелә торган документларны, кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, карап тикшермичә генә кире кайтара. Бу очракта планлаштырылган төзелеш турында хәбәрнамә юнәлтелмәгән дип санала.

3. Планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә кергән көннән алып җиде эш көне эчендә, әлеге мадднең 8 өлешендә каралган очрактан гайре, төзелешкә рөхсәтнамә бирүгә вәкаләтле җирле үзидарә органы:

- индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларын планлаштырыла торган төзү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының җирдән файдалану һәм төзелеш объектларын үзгәртеп кору кагыйдәләренең, территорияне планлаштыру документларының һәм капиталь төзелеш объектларының әлеге Кодекс,

башка федераль законнар белән билгеләнгән параметрларына мәҗбүри таләпләргә һәм планлаштырылган төзелеш турында хәбәрнамә килү датасына гамәлдә булган мәҗбүри таләпләргә туры килү-килмәүне тикшерә, шулай ук, җир кишәрлеген рөхсәт ителгән файдалану һәм Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләүләр нигезендә, индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкинлеген дә;

- төзүчегә планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә билгеләнгән ысул белән индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштырумөмкинлеге йә индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларының планлаштырыла торган төзү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларга туры килмәве һәм (яки) индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштырырга мөмкин булмау турында хәбәрнамә җибәрә.

Индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыру мөмкинлеге йә индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларының планлаштырыла торган төзү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларга туры килмәве һәм (яки) индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштырырга мөмкин булмау турында хәбәрнамә рәвешләре төзелеш, архитектура, шәһәр төзелеше өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан раслана.

Әгәр индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырыла һәм планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә үрнәк архитектура чишелешенә күрсәтмә булмыйча аның нигезендә индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты төзү яисә реконструкцияләү планлаштырыла икән, төзелешкә рөхсәт бирүгә вәкаләтле җирле үзидарә органы:

- әлеге маддәнең 6 өлешендә каралган кире кайтару өчен нигезләр булмаганда әлеге хәбәрнамә кергән көннән алып өч эш көненнән дә артыграк булмаган срокта, шул исәптән ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасын һәм аңа тоташа торган ведомствоара электрон багланышларның региональ системаларын кулланып, күрсәтелгән хәбәрнамәне һәм аңа кушымта итеп бирелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының тышкы кыяфәте тасвирламасын мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органына җибәрә;

- әлеге хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларының рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән чик параметрларына, территорияне планлаштыру документларына һәм РФ ШтК билгеләгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына, башка федераль законнарга һәм әлеге хәбәрнамә килү датасына гамәлдә булган капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата куелган мәҗбүри таләпләргә туры килү-килмәүне, шулай ук индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану һәм Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән һәм әлеге хәбәрнамә керү датасына гамәлдә булган чикләүләр нигезендә урнаштыруның мөмкинлеген тикшерә.
- әлеге хәбәрнамә килгән көннән соң егерме эш көненнән дә соңга калмыйча, төзүчегә әлеге маддәнең 7 өлешендәге 2 пунктында каралган әлеге хәбәрнамәдә билгеләнгән ысул белән индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларын планлаштырыла торган төзү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакчайортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге яисә индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларының планлаштырыла торган төзү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларга туры килмәве һәм (яки) индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштырырга мөмкин булмау турында хәбәрнамә җибәрә.

1. Индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының параметрларын планлаштырыла торган төзү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларына туры килмәве һәм (яисә) индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкин булмау турында хәбәрнамә төзүчегә түбәндәге очракта гына җибәрелә, әгәр:

- хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларының рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән чик параметрларына, территорияне планлаштыру документларына һәм РФ ШтК билгеләгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына, башка федераль законнарга һәм әлеге хәбәрнамә килү датасына гамәлдә булган капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата куелган мәҗбүри таләпләргә туры килмәсә;
- индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану һәм Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән һәм әлеге хәбәрнамә керү датасына гамәлдә булган чикләүләр нигезендә урнаштыру мөмкин булмаса;
- планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә төзүче булмаган зат тарафыннан бирелгән яисә җир кишәрлегенә хокукы булмауга бәйле рәвештә җибәрелгән булса;

- әлеге маддәнең 9 өлешендә күрсәтелгән срокта мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органыннан индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының тышкы кыяфәте тасвирламасының тарихи җирлекне саклау предметына һәм капиталь төзелеш объектларының архитектур чишелешләренә карата федераль яисә региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә урнашкан территориаль зонага карата шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве турында хәбәрнамә килсә.

2.Индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларын планлаштырылган төзү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларына туры килмәве һәм (яисә) индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкин булмау турында хәбәрнамәдә төзүчегә рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрларын күрсәтеп, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, территорияне планлаштыру документлары белән мондый хәбәрнамәне җибәрүнең барлык нигезләре булырга тиеш, РФ Шәһәр төзелеше кодексы, башка федераль законнар белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләр һәм мәҗбүри таләпләр планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә кергән көнгә гамәлдә булган һәм планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының параметрларына туры килми торган, шулай ук индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштырыру мөмкин булмаган очракта – индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яисә реконструкцияләү рөхсәт ителми торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануның билгеләнгән төре, җир кишәрлегеннән файдалануны чикләү төрләре, шуларга бәйле рәвештә индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектын төзү яисә реконструкцияләү рөхсәт ителми, яки планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәне биргән яисә җибәргән затның җир кишәрлегенә хокуклары булмау сәбәпле, төзүче булып тормавы турында мәгълүматлар.

Төзүчегә әлеге маддәнең 10 өлешендәге 4 пунктында каралган нигез буенча мондый хәбәрнамәне җибәргәндә, аңа мәҗбүри кушымта булып, индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының тышкы кыяфәте тасвирламасының тарихи җирлекне саклау предметына һәм капиталь төзелеш объектларының шәһәр төзелеше регламенты белән федераль яки региональ әһәмияттәге территориаль зонага карата билгеләнгән архитектура чишелешләренә туры килмәве турында хәбәрнамә тора.

3. Төзүче тарафыннан индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларының планлаштырыла торган төзелеше турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның туры килүе һәм җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкинлеге турында төзелешкә рөхсәт бирүгә вәкаләтле җирле үзидарә

органыннан хәбәрнамә алу  яисә күрсәтелгән органның әлеге маддәнең 7 өлешендә яки  8 өлешенең 3 пунктында каралган срокта индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларын планлаштырылган төзү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларына туры килмәве һәм (яисә) индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыру мөмкин булмавы турында  хәбәрнамә җибәрмәве күрсәтелгән органнар тарафыннан индивидуаль торак төзелеше яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү объектын яки бакча йортын төзү яисә үзгәртеп коруны килештерү дип санала һәм төзүчегә планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрлар нигезендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзүне яки реконструкцияләүне төзүче тарафыннан әлеге маддәнең  1 өлеше нигезендә планлаштырыла торган төзелеш турында мондый хәбәрнамә җибәргәннән соң ун ел эчендә башкару хокукы бирә. Әлеге хокук, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51.1 маддәсе 21 өлешенең 1 - 3 пунктларында каралган очраклардан гайре, җир кишәрлегенә һәм индивидуаль торак төзелеше объектына яисә бакча йортына хокуклар күчкәндә саклана. Шул ук вакытта планлаштырылган төзелеш турында яңа хәбәрнамә җибәрү таләп ителми.

Индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йортын төзү яки реконструкцияләү параметрлары үзгәргән очракта, төзүче әлеге маддәнең 1 өлешендә күрсәтелгән ысуллар белән, бу хакта төзелешкә рөхсәтләр бирүгә вәкаләтле җирле үзидарә органына, үзгәртелә торган параметрларны күрсәтеп, хәбәрнамә җибәрә. Күрсәтелгән хәбәрнамәне карау әлеге маддәнең 4-13 өлешләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Төзүче тарафыннан индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларының планлаштырыла торган төзелеше турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның туры килүе һәм җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкинлеге турында төзелешкә рөхсәт бирүгә вәкаләтле  җирле үзидарә органыннан хәбәрнамә алу  яисә күрсәтелгән органның әлеге маддәнең 7 өлешендә яки  8 өлешенең 3 пунктында каралган срокта индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларын планлаштырылган төзү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларына туры килмәве һәм (яисә) индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыру мөмкин булмавы турында  хәбәрнамә җибәрмәү очрагында планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрлар нигезендә төзелгән яисә реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының билгеләнгән таләпләренә туры китерү һәм сүтү белән китерелгән зыяннар, мондый индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын, аларның рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларына туры килмәве, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән

капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү аркасында, үз белдеге белән төзелгән дип тануга бәйле рәвештә, яисә РФ Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата йә мондый индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын урнаштыруның Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән һәм планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәр килү датасына гамәлдә булган чикләүләргә туры килмәве аркасында мәҗбүри таләпләргә туры килмәве индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырыла торган параметрлары турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырыла торган параметрлары турында хәбәрнамәне җибәргән яисә әлеге маддәнең 7 өлешендәге яисә 8 өлешенең 3 пунктында каралган срокта вазифаны үтәмәгән очракта, күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырыла торган төзелешләре турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларына туры килмәве һәм (яисә) индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруның рөхсәт ителмәве хакында хәбәрнамә җибәрмәгән җирле үзидарә органының вазифаи затының гаебе суд тарафыннан билгеләнгән очракта, муниципаль берәмлек казнасы исәбеннән тулысынча түләтелергә тиеш”;
1.65) 28 маддәнең 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Төзелешне башкаручы зат, төзүче, техник заказчы, бинаны, корылманы эксплуатацияләүгә җаваплы зат яки региональ оператор (төзелеш подряды шартнамәсе нигезендә төзелеш, реконструкцияләү, капиталь ремонт башкарылган очракта) биреме, проект документациясе, җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт ителгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын төзүгә рөхсәт алу датасына билгеләнгән капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә таләпләр, Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләүләр, техник регламентлар таләпләре нигезендә билгеләнгән чикләүләр белән булган нигездә, капиталь төзелеш объектын төзүне, реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны башкарырга тиешһәм шул ук вакытта өченче затлар һәм әйләнә-тирә мохит өчен эшләрнең куркынычсызлыгын, хезмәт куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне, мәдәни мирас объектларының сакланышын тәэмин итәргә.Төзелешне башкаручы зат шулай ук капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау башкарыла торган территориягә, төзүче, техник заказчы, бинаны, корылманы эксплуатацияләү өчен җаваплы зат, яки региональ оператор, дәүләт төзелеш күзәтчелеге органнары вәкилләренә керү мөмкинлеген тәэмин итәргә бурычлы,аларга кирәкле документларны тапшырырга, төзелеш контролен үткәрергә, башкарма документацияне алып баруны тәэмин итәргә, төзүчегә, техник заказчыга, бинаны, корылманы эксплуатацияләүгә җаваплы затка, яки региональ операторга, дәүләт төзелеш күзәтчелеге органнары вәкилләренә тикшерелергә тиешле эшләрне төгәлләү сроклары турында хәбәр итәргә, ачыкланган җитешсезлекләрне бетерүне

тәэмин итәргә һәм ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү турында актлар төзегәнче эшләрне дәвам итәргә керешмәскә, кулланыла торган төзелеш материалларының сыйфатын тикшереп торуны тәэмин итәргә”;

1.66) 28 маддәнең 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Кирәклеге мондый объектны төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау барышында ачыкланган капиталь төзелеш объекты параметрларының проект документларыннан тайпылуы төзүче, техник заказчы, бинаны, корылманы эксплуатацияләү өчен җаваплы зат яисә проект документациясенең региональ операторы яңа раслаган проект документлары нигезендә аңа Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертелгәннән соң гына рөхсәт ителә”;

1.67) Кагыйдәләрнең 28 маддәсендә 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Төзелеш контроле башкарылучы эшләрнең проект документларына,җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын төзүгә рөхсәт алу өчен бирелгән датага билгеләнгән капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә карата таләпләргә, техник регламентларның таләпләренә, инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре таләпләренә туры килүен тикшерү максатларында капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау процессында башкарыла (шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләрен һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеше таләпләрен үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән карарларга һәм чараларга),шулай ук җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт ителгән һәм Россия Федерациясенең Җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләүләргә бәйле.

Төзелеш контролен төзелеш эшләрен башкаручы зат гамәлгә ашыра.

Төзелеш, реконструкцияләү, капиталь ремонт төзелеш подряды шартнамәсе нигезендә гамәлгә ашырылу очрагында, төзелеш контроле төзүче, техник заказчы, бинаны, корылманы эксплуатацияләүгә җаваплы зат яки региональ оператор тарафыннан яисә килешү нигезендә алар тарафыннан җәлеп ителә торган шәхси эшмәкәр яки юридик зат тарафыннан үткәрелә.

Төзүче яки техник заказчы үз инициативасы буенча проект документациясен әзерләүне гамәлгә ашыручы затны башкарылучы эшләрнең проект документларына туры килүен тикшерү өчен җәлеп итә ала.

Реконструкцияләү тулысынча яки өлешчә федераль бюджет акчалары хисабына башкарылу планлаштырылган капиталь төзелешнең аерым объектларына каратаРоссия Федерациясе Хөкүмәте, ул билгеләгән очракларда, төзелеш, архитектура, шәһәр төзелеше өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы яисә күрсәтелгән органга буйсынган дәүләт (бюджет яки автоном) учреждениесе тарафыннан төзелеш контролен үткәрү турында карар кабул итә.

Төзелешне башкаручы зат капиталь төзелеш объектында авария хәленең һәр очрагы турында дәүләт төзелеш күзәтчелеге органнарына хәбәр итәргә тиеш.

Капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау процессында төзүче зат тарафыннан (төзелешне башкаручы зат һәм төзүче, техник заказчы, бинаны, корылманы эксплуатацияләү өчен җаваплы зат яисә региональ оператор тарафыннантөзелеш подряды шартнамәсе нигезендәтөзелеш, реконструкцияләү, капиталь ремонтны гамәлгә ашыру очрагында)капиталь төзелеш объектының иминлегенә йогынты ясый торган һәм төзелеш, реконструкция, капиталь ремонт технологиясе нигезендә башкарылган эшләрнең үтәлешен контрольдә тоту башка эшләрне башкарганнан соң башкарылырга тиеш түгел,шулай ук төзелеш конструкцияләренең һәм инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләре участокларының куркынычсызлыгына, әгәр төзелеш контролен үткәрү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү инженер-техник тәэмин итү челтәрләренең башка төзелеш конструкцияләрен һәм участокларын сүтү яки җимерүсез мөмкин булмаса, күрсәтелгән эшләрнең, конструкцияләрнең һәм челтәрләрнең техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә туры килүе мөмкин түгел.

Төзелеш конструкцияләренең куркынычсызлыгына контрольлек иткәнче, мондый конструкцияләрнең иминлегенә йогынты ясый торган һәм төзелеш, реконструкция, капиталь ремонт технологиясе нигезендә, башка эшләрне башкарганнан соң башкарылмый торган барлык эшләрнең үтәлешен контрольдә тоту башкарылырга тиеш,шулай ук проект документларында, техник регламентлар таләпләрендә каралган очракларда мондый конструкцияләрне сынау үткәрелергә тиеш.Күрсәтелгән эшләрнең үтәлешен, күрсәтелгән конструкцияләрнең, инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең участокларының куркынычсызлыгына контрольлек итү нәтиҗәләре буенча күрсәтелгән эшләрне, конструкцияләрне, инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләре участокларын тикшерү актлары төзелә.

Инженер-техник тәэмин итү челтәрләренең, конструкцияләренең, участокларны тикшерү нәтиҗәләре буенча җитешсезлекләр беленгәндә төзүче яки техник заказчы күрсәтелгән эшләрнең үтәлешен, күрсәтелгән конструкцияләрнең, инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең, участокларының куркынычсызлыгын тикшереп торуны таләп итә ала.Мондый эшләрне, конструкцияләрне, инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең участокларын тикшерү актлары ачыкланган җитешсезлекләрне бетергәннән соң гына төзелергә тиеш.

Башка эшләрне башкару тиешле контроль үткәрелгәннән соң алты айдан соң башланырга тиеш булган очракларда, капиталь төзелеш объектының иминлегенә йогынты ясый торган эшләрнең үтәлешен контрольдә тотуһәм төзелеш, реконструкция, капиталь ремонт технологиясе нигезендә, аларның үтәлеше башка эшләрне башкарганнан соң контрольдә тотылырга тиеш булмаганлыктан,шулай ук төзелеш конструкцияләренең һәм инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләре участокларының

куркынычсызлыгы өчен төзелеш контролен үткәрү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү башка төзелеш конструкцияләрен һәм инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләре участокларын сүтү яки җимерүдән башка мөмкин булмаса,тиешле актлар төзү белән кабат үткәрелергә тиеш.

Төзүче, техник заказчы, бинаны, корылманы эксплуатацияләү өчен җаваплы зат яки региональ операторның, проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы затларның, капиталь төзелеш объектын төзегәндә, реконструкцияләгәндә, капиталь ремонтлаганда эшләрнең җитешсезлекләре турында замечаниеләре язма рәвештә рәсмиләштерелергә тиеш.Күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерү турында акт төзелә, ул күрсәтелгән җитешсезлекләр турында замечаниеләрне күрсәткән зат һәм төзелешне башкаручы зат тарафыннан имзалана.

Капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору тәмамланганнан соң, шәхси торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзү, реконструкцияләү очракларыннан гайре, төзелешне башкаручы зат тарафыннан (төзелешне гамәлгә ашыручы зат, төзүче яисә техник заказчы, төзелеш подряды шартнамәсе нигезендә төзелеш, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырган очракта, шулай ук төзелеш контролен гамәлгә ашыручы зат тарафыннан, шартнамә нигезендә төзелеш контролен гамәлгә ашырган очракта) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының параметрларының проект документациясе таләпләренә (шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләрен һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеше таләпләрен үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән карарлар һәм чаралар) туры килүен раслый торган актка кул куела.Төзелеш контролен үткәрү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.”

1.68) 28 маддәнең 10 өлешендә 4 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы тарафыннан төзелешне гамәлгә ашыручы затка ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү турында күрсәтмә бирү өчен нигез булып торучы акт төзелә.Күрсәтмәдә бозу төре күрсәтелә, норматив-хокукый актка сылтама, техник регламент, таләпләре бозылган проект документлары күрсәтелә, шулай ук ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү вакыты (срогы) билгеләнә.Күрсәтелгән вакытка капиталь төзелеш объектын төзүне, реконструкцияләүне туктатып тору Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла”;

1.69) 28 маддәнең 10 өлешендә 5 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә, әлеге кодекста каралган дәүләт төзелеше күзәтчелегеннән тыш, дәүләт күзәтчелегенең башка төрләрен гамәлгә ашыру рөхсәт ителми,шулай ук Россия Федерациясенең аерым икътисади зонасында төзелә торган объектларга карата,Россия Федерациясенең континенталь шельфында, эчке

диңгез суларында, Россия Федерациясенең территориаль диңгезендә, аеруча саклаулы табигать территорияләре чикләрендә, су объектларында ясалма җир кишәрлекләрендә Федераль дәүләт экологик күзәтчелеген һәммәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләр алып барганда мәдәни мирас объектларының торышы, аларны карап тоту, саклау, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклау күзәтчелеген,әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә I категорияле объектларга караган капиталь төзелеш объектларын төзегәндә,реконструкцияләгәндә гамәлгә ашыру;”;

1.70) 28 маддәнең 10 өлешендә 6 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт төзелеше күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибе дәүләт төзелеше күзәтчелеген гамәлгә ашырганда, шәхси эшмәкәрләр булмаган физик затларның эшчәнлеген тикшерүне оештыру һәм үткәрү тәртибен дә кертеп, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә”;

1.71) 28 маддәнең 9 өлешенең 1 пунктында “модификацияләнгән проект документы булып тора” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.72) 28 маддәнең 10 пунктында “техник регламентларның” сүзләрен төшереп калдырырга, “энергетик нәтиҗәлелеген” сүзләреннән соң “энергетика нәтиҗәлелеге таләпләре кагылмый торган капиталь төзелеш объектларыннан гайре)” сүзләрен өстәргә;

1.73) 28 маддәнең 11 өлешендә икенче абзацны түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга:

“Төзү, реконструкцияләү тулысынча яки өлешчә федераль бюджет акчалары хисабына башкару планлаштырылган капиталь төзелешнең аерым объектларына карата Россия Федерациясе Хөкүмәте, ул билгеләгән очракларда, төзелеш, архитектура, шәһәр төзелеше өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы яисә күрсәтелгән органга буйсынган дәүләт (бюджет яки автоном) учреждениесе тарафыннан төзелеш контролен үткәрү турында карар кабул итә.”;

1.74) 29 маддәнең 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында карар кабул итү өчен түбәндәге документлар кирәк:

1. җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар, шул исәптән сервитутны билгеләү турында шартнамә, гавами сервитутны билгеләү турында карар;

2. төзелешкә рөхсәт алу өчен җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы яки линияле объектны төзү, реконструкцияләү очрагында, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан гайре), урнаштыру өчен җир кишәрлеге төзү таләп ителми торган линияле объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирелгән очракта территорияне планлаштыру проекты;

3. төзелешкә рөхсәтнамә;

4. капиталь төзелеш объектын кабул итү акты (төзелеш подряды шартнамәсе нигезендә төзелеш, реконструкцияләү башкарылган очракта);

5. төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объекты параметрларыныңпроект документациясенә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектын файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән тәэмин итү таләпләренә туры килүен раслый торган һәм төзелешне гамәлгә ашыручы зат тарафыннан кул куелган акт (төзелешне гамәлгә ашыручы зат, төзелеш подряды шартнамәсе нигезендә төзү, реконструкцияләнү гамәлгә ашырылган очракта төзүче яисә техник заказчы тарафыннан, шулай ук шартнамә нигезендә төзелеш контроле башкарылган очракта төзелеш контролен гамәлгә ашыручы зат тарафыннан);

6. төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының техник шартларга туры килүен раслаучы һәм инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләрен эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы оешмалар вәкилләре тарафыннан имзаланган документлар (алар булган очракта);

7. төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының урнашуын, җир кишәрлеге чикләрендә инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләрен һәм җир кишәрлеген планлаштыруны чагылдыра торган һәм төзелешне гамәлгә ашыручы зат тарафыннан имзаланган схема (төзүне гамәлгә ашырган зат тарафыннан, төзелеш подряды шартнамәсе нигезендә төзелеш, реконструкцияләү башкарылган очракта төзүче яисә техник заказчы тарафыннан),линия объектын төзү, реконструкцияләү очракларыннан гайре;

8. төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының проект документациясе таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектын файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән тәэмин итү таләпләренә туры килүе турында дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы бәяләмәсе(Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 маддәсенең 1 өлеше нигезендә дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру каралган очракта), федераль дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы (алга таба - федераль дәүләт экология күзәтчелеге органы) бәяләмәсе, ул Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 маддәсенең 7 өлешендә каралган очракларда бирелә;

9. хәтәр объект хуҗасының куркыныч объектта авария нәтиҗәсендә зыян китергән өчен граждан җаваплылыгын куркыныч объекттагы авария нәтиҗәсендә зыян китергән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә куркыныч объект хуҗасының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләү турында мәҗбүри иминиятләү шартнамәсе төзүне раслый торган документ;

10.мәдәни мирас объектларын саклауның тиешле “Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында” 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән орган тарафыннан расланган мәдәни мирас объектын саклап

калу буенча бу объектны реставрацияләгәндә, консервацияләгәндә, ремонтлаганда һәм заманча файдалануга яраклаштырганда башкарылган эшләрне кабул итү акты.

11.“Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәве турында” 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әзерләнгән капиталь төзелеш объектының техник планы.

1.75) Кагыйдәләрнең 29 маддәсенең 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Төзелешкә рөхсәт биргән орган объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза кергән көннән алып җиде эш көне эчендә әлеге маддәнең 3 өлешендә күрсәтелгән документларның булуын һәм дөрес рәсмиләштерелүен тикшерүне, капиталь төзелеш объектын карауны тәэмин итәргә һәм мөрәҗәгать итүчегә объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирергә яисә, кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, мондый рөхсәт бирүне кире кагарга тиеш.Төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектын карау барышында мондый объектның төзелешкә рөхсәттә күрсәтелгән таләпләргә, капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә карата шәһәр төзелеше планын төзүгә рөхсәт алу датасына билгеләнгән таләпләргәяисә линияле объектны төзегән, реконструкцияләгән очракта территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты таләпләренә (линияле объектнны төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру документларын әзерләү таләп ителмәгән очраклардан гайре), урнаштыру өчен җир кишәрлеге төзелү таләп ителми торган линияле объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирелгән очракта территорияне планлаштыру проектында билгеләнгән таләпләргә,шулай ук җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт ителгән, Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләүләргә, проект документациясе таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектын файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән тәэмин итү таләпләренә туры килүен тикшерү гамәлгә ашырыла.Капиталь төзелеш объектын төзегәндә, реконструкцияләгәндә, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 54 маддәсенең 1 өлеше нигезендә дәүләт төзелеш күзәтчелеге гамәлгә ашырылса, мондый объектны төзүгә рөхсәт биргән орган тарафыннан карау үткәрелми”;

1.76) Кагыйдәләрнең 29 маддәсенең 5 өлешендә 3 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Капиталь төзелеш объектының шәһәр төзелеше планын төзүгә, реконструкцияләүгә тәкъдим ителгән җир кишәрлеген төзү өчен рөхсәт алу датасына билгеләнгән таләпләргәяисә линия объектын төзегән, реконструкцияләгән, капиталь ремонтлаган очракта территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты таләпләренә (линия объектын төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру документларын әзерләү таләп ителмәгән очраклардан гайре), урнаштыру өчен җир кишәрлеге кирәк булмаган линияле объектны файдалануга кертүгә

рөхсәт бирелгән очракта территорияне планлаштыру проектында билгеләнгәнгә туры килмәве”;

1.77) Кагыйдәләрнең 5 маддәсенең 5 өлеше 5 абзацында “Әлеге нигез индивидуаль торак төзелеше объектларына карата кулланылмый” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.78) 29 маддәдә 5 өлешнең алтынчы, җиденче абзацларны көчен югалткан дип танырга;

1.79) 29 маддәнең 5 өлешен түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

“Капиталь төзелеш объектының җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт ителгән файдалануга һәм (яки) Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирелгән көнгә билгеләнгән чикләүләргә туры килмәве,күрсәтелгән чикләүләр РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 маддәсендәге 7 өлешенең 9 пунктында каралган очракларда кабул ителгән территориядән файдалануның махсус шартлары булган зонаны билгеләү яисә үзгәртү турындагы карар белән каралган очраклардан гайре,һәм территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона урнаштырылуга яисә үзгәртелүгә бәйле рәвештә төзелә торган, реконструкцияләнә торган капиталь төзелеш объекты эксплуатациягә кертелмәгән”;

1.80) 30 маддәнең 2 өлешен түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

“-шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында күрсәтелгән территорияләрдән, мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләренең урнашу урыны турында мәгълүматларның бердәй дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында күрсәтелгән зоналар, территорияләр чикләренең урнашу урынын тасвирлауга туры килмәве;

- федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге истәлекле урыннар территорияләреннән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләрендә тулысынча яисә өлешчә урнашкан җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның күчемсез мөлкәт объектларыннан мондый зоналар, территорияләр чикләрендә файдалану чикләүләренә шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән чикләүләрнең туры килмәве;

- территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона яшәвен билгеләү, үзгәртү, туктату, мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен, федераль әһәмияттәге тарихи җирлек территориясен, региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясен билгеләү, үзгәртү”;

1.81) 30 маддәнең 8 өлешен “,күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестры мәгълүматларына, шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системаларында булган мәгълүматларга, документларга һәм материалларга” сүзләре белән тулыландырырга;

1.82) 30 маддәнең 10 өлешендә “үткәрүнең” сүзләреннән соң “җәмәгатьчелек фикер алышуларының яки” сүзләре белән тулыландырырга.

1.83) 30 матдәнең 11 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар муниципаль берәмлек уставында һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 һәм 28 маддәләре һәм әлеге маддәнең 12 һәм 13 өлешләре нигезендә уздырыла”;

1.84) Кагыйдәләрнең 30 маддәсенең 12 пунктын “дәвамлылык”сүзеннән соң “җәмәгатьчелек фикер алышуларын яки” сүзләре белән тулыландырырга;

1.85) Кагыйдәләрнең 30 маддәсенең 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә ачык (гавами) тыңлаулар тәмамлангач, комиссия, шундый җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектына үзгәрешләр кертүне тәэмин итә һәм күрсәтелгән проектны җирле администрация башлыгына тапшыра.Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектына мәҗбүри кушымталар булып җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар беркетмәсе һәм җәмәгатьчелек фикер алышулары яки гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә тора, аларны РФ ШтК нигезендә үткәрү таләп ителмәгән очраклардан гайре";

1.86) 30 маддәнең 15 өлешендә икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Кагыйдәләргә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Анатыш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы тарафыннан раслана.Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектына мәҗбүри кушымталар булып җәмәгатьчелек фикер алышулары яки ачык тыңлаулар беркетмәсе, җәмәгатьчелек фикер алышулары яки гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә, әгәр аларны РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә уздыру таләп ителми икән, искәрмә булып тора”;

1.87)30 маддәнең 17 өлешен “нигезендә” сүзеннән соң “җәмәгатьчелек фикер алышулары нәтиҗәләре яисә” сүзләре белән тулыландырырга;

1.88) 30 маддәне түбәндәге эчтәлектәге 21 өлеш белән тулыландырырга:

“21. Җирле үзидарә органына дәүләт хакимияте башкарма органыннан, вазифаи заттан, дәүләт учреждениесеннән яисә җирле үзидарә органыннан үз белдеге белән төзелгән корылманы ачыклау турында хәбәрнамә кергән көннән башлапчикләрендә шундый корылма урнашкан территориаль зонага карата куллану кагыйдәләрен, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрен, рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларын, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүне күздә тоткан үзгәрешләр кертү рөхсәт ителми,әлеге хәбәрнамәне җирле үзидарә органы тарафыннан карау нәтиҗәләре буенча дәүләт хакимиятенең

башкарма органына, вазифаи затка, дәүләт учреждениесенә яисә җирле үзидарә органына әлеге хәбәрнамә кергән очраклардан тыш, аны сүткән яисә билгеләнгән таләпләргә туры китергәнчегә кадәр, әлеге хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча дәүләт хакимияте башкарма органына, вазифаи затка, дәүләт учреждениесенә яисә җирле үзидарә органына җибәргән очраклардан тыш, ә үз белдеге белән төзелгән билгеләр каралмый яисә судның үз белдеге белән корылган корылманы сүтү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турындагы дәгъва таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тарту турындагы карары законлы көченә керә.”;

1.89) 30 маддәне түбәндәге эчтәлектәге 22 өлеш белән тулыландырырга:

“22.30 маддәсендәге 2 өлешнең алтынчы, җиденче, сигезенче абзацларында каралган очракларда дәүләт хакимияте башкарма органы яисә җирле үзидарә органы территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарны, мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен билгеләүгә, федераль әһәмияттәге тарихи җирлекләр, региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләрен раслауга вәкаләтле орган җирле администрация башлыгына территорияләрдән, мәдәни мирас объектлары территорияләреннән, федераль әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләреннән, региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләреннән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләрен аерып алу өлешендә җирләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү, мондый зоналар, территорияләр чикләрендә җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануны чикләү билгеләү турындагы таләп җибәрә.

Күрсәтелгән очракта, шулай ук территориядән файдалануның аерым шартлары булган зонаның чикләрен билгеләү, үзгәртү яки яшәүдән туктату турындагы мәгълүматларның хокукларын теркәү органыннан кергән очракта йә әлеге маддәнең 2 өлешендәге алтынчы, җиденче, сигезенче абзацларында каралган нигезләрнең ачыкланган көннән Балык Бистәсе муниципаль районы “Анатыш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында карар кабул итәргә тиеш.

Мәдәни мирас объектлары территорияләре, федераль әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре, тарихи җирлекләр территорияләре чикләрен билгеләү, мондый зоналар, территорияләр чикләрендә җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын куллануны чикләүләрне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү вакыты дәүләт хакимиятенең башкарма органы яисә җирле үзидарә органыннан кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турындагы таләпләр кергән көннән алты айдан артмаска тиеш,территорияләрне, мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен билгеләүгә, федераль әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләрен раслауга, территориядән файдалануның аерым шартлары булган зонаны билгеләү, үзгәртү яки туктату турындагы мәгълүматларны теркәү органыннан кертү йә әлеге маддәнең 2 өлешендәге алтынчы, җиденче, сигезенче абзацларында

каралган кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү өчен нигезләрнең ачыкланган көненнән алып гамәлгә ашырыла.”;

1.90) Кагыйдәләрне түбәндәге эчтәлектәге 30.1 маддәсе белән тулыландырырга:

“30.1. Җәмәгатьчелек фикер алышулары, генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне ызанлау проектлары буенча гавами тыңлаулар, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә яисә объектка рөхсәт бирү турында карар проектларына, рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турында карар проектлары буенча.

1. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне ызанлау проектлары буенча җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре уңай шартларга, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектларга, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә, рөхсәт бирү турындагы карарларның проектларына, рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектларына (алга таба шулай ук әлеге статьяда - проектлар) җирлек Уставы һәм (яисә) норматив хокукый акты һәм җирлек Советының нигезләмәләрен исәпкә алып, РФ Шәһәр төзелеше кодексында каралган җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә ачык тыңлаулар үткәрелә.

2. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне межалау проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда катнашучылар булып әлеге проектлар әзерләнгән территориядә даими яшәүче гражданнар, әлеге территория чикләрендә булган җир кишәрлекләренә һәм (яки) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларына хокук ияләре, шулай ук әлеге капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарга ия булучылар тора.

Җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турындагы карар проектлары, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның чик параметрларыннан кире кагуга рөхсәт бирү турындагы карар проектлары буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларында яки гавами тыңлауларында катнашучылар булып гражданнар тора, әлеге проектлар әзерләнгән, әлеге территориаль зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлеге яки капиталь төзелеш объекты территориаль зона чикләрендә даими яшәүче, әлеге территориаль зона чикләрендә булган җир кишәрлекләренең һәм (яки) аларда

урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокуклары ияләре, әлеге проектлар әзерләнгән, мондый җир кишәрлекләренә ия булган яки аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларына ия булган, капиталь төзелеш объектының бер өлеше булып торган биналарга ия булган, аларга карата әлеге проектлар әзерләнгән, әлеге объектлар әзерләнгән җир кишәрлеге чикләрендә даими яшәүче, ә РФ Шәһәр төзелеше кодексының 39 маддәсенең 3 өлешендә каралган очракта, шулай ук әлеге проектларны тормышка ашыру нәтиҗәсендә әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясау куркынычы янаган җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокукына ия булучылар тора.

Җәмәгатьчелек фикер алышуларын уздыру процедурасы түбәндәге этаплардан тора:

- җәмәгатьчелек фикер алышулары башлану турында хәбәр итү;

-җәмәгатьчелек фикер алышуларында каралырга тиешле проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирле үзидарә вәкаләтле органының рәсми сайтында (алга таба-әлеге маддәдә – рәсми сайт) урнаштыру һәм (яисә) дәүләт яисә муниципаль мәгълүмат системасында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып (алга таба шулай ук – “Интернет” челтәре), яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталында (алга таба әлеге маддәдә – мәгълүмати системалар) җәмәгатьчелек фикер алышулары уздыруны һәм мондый экспозицияләрне яисә экспозицияләрне ачуны тәэмин итү;

- җәмәгатьчелек фикер алышуларында каралырга тиешле проект экспозициясен яисә экспозицияләрен үткәрү;

- җәмәгатьчелек фикер алышулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;

- җәмәгатьчелек фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм игълан итү.

Җәмәгатьчелек фикер алышулары яки ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр итү үз эченә алырга тиеш:

-җәмәгатьчелек фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект турында мәгълүмат һәм мондый проектка карата мәгълүмати материаллар исемлеге;

-җәмәгатьчелек фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларын яисә ачык тыңлауларын үткәрү тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат;

- җәмәгатьчелек фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда каралырга тиеш булган экспозициянең яисә проект экспозицияләренең урыны, датасы турында, мондый проектның экспозициясен яки экспозицияләрен үткәрү вакыты турында, күрсәтелгән экспозицияләрне яки экспозицияләрне карау мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат;

-җәмәгатьчелек фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, вакыты һәм формасы турында мәгълүмат.

7. Җәмәгатьчелек фикер алышулары башлану турында хәбәрнамәдә шулай ук җәмәгатьчелек фикер алышуларда каралырга тиешле проект һәм аңа карата мәгълүмати материаллар урнаштырылган рәсми сайт турында, мондый проект һәм аңа мәгълүмати материаллар урнаштырылачак, аларны кулланып җәмәгатьчелек фикер алышулары уздырылачак мәгълүмати системалармәгълүматы булырга тиеш.Гавами тыңлаулар башлану турында хәбәрнамәдә шулай ук гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект урнаштырылган рәсми сайт турында мәгълүмат һәм аңа карата мәгълүмат материаллары, җыелыш яисә гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышын яисә җыелышларын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүмат булырга тиеш.

Җәмәгатчелек фикер алышулары яки гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү:

- җәмәгатчелек фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектның рәсми сайтында яки мәгълүмат системаларында урнаштырыласы көнгә кадәр җиде көннән дә соңга калмыйча,муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми игълан итү өчен билгеләнгән тәртиптә, шулай ук муниципаль хокукый актларда, бүтән гаммәви мәгълүмат чараларында каралган очракта, бастырып чыгарылырга тиеш;

-җирле үзидарә органының җәмәгатьчелек фикер алышуларын яки гавами тыңлауларын үткәрүгә вәкаләтле бинасы янында, гражданнар күпләп җыела торган урыннарда һәм әлеге маддәнең 3 өлешендә күрсәтелгән тиешле проектлар әзерләнгән территориядә (алга таба – әлеге маддәнең 3 өлешендә күрсәтелгән территория) һәм (яисә) территория зоналары чикләрендә (алга таба – җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар үткәрелә торган территория), җәмәгатьчелек фикер алышуларында катнашучыларның әлеге мәгълүматка керү мөмкинлеген тәэмин итүче яисә гавами тыңлауларның башка ысуллары белән урнашкан башка урыннарда җиһазландырылган мәгълүмати стендларда тарала.

Әлеге маддәнең 4 өлешендәге 2 пункты һәм 5 өлешендәге 2 пункты нигезендә урнаштыру чоры дәвамында җәмәгатьчелек фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект һәм аңа мәгълүмати материалларның проект экспозициясе уздырыла.Экспозиция эше барышында экспозициягә килүчеләргә консультация бирү, җәмәгатьчелек фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект турында мәгълүмати материаллар тарату оештырылырга тиеш.Экспозициягә килүчеләргә консультация бирү җирле үзидарә органының яисә ул төзегән коллегиаль киңәшмә органы (алга таба – җәмәгатьчелек фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны оештыручы) һәм (яисә) җәмәгатьчелек фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектны эшләүче вәкилләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8. Әлеге маддәнең 5 өлешендәге 4 пунктына һәм 2 пунктына туры китереп урнаштыру чорында җәмәгатьчелек фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектны һәм аңа карата мәгълүмати материалларны урнаштыру һәм мондый проектның экспозицияләрен үткәрү чорында әлеге маддәнең 12 өлеше нигезендә идентификация (таныклау) үткән җәмәгатьчелек фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда катнашучылар мондый проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- рәсми сайт яисә мәгълүмат системалары ярдәмендә (җәмәгатьчелек фикер алышулары үткәрелгән очракта);
- гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышын яисә җыелышларын уздыру барышында язма яисә телдән рәвештә (гавами тыңлаулар үткәрелгән очракта);
- җәмәгатьчелек фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны оештыручы адресына язма рәвештә;
- җәмәгатьчелек фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләрне китапта (журналда) исәпкә алу юлы белән.

9. Әлеге маддәнең 10 өлеше нигезендә кертелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, әлеге маддәнең 15 өлешендә каралган очрактан гайре, җәмәгатьчелек фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны оештыручы тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш.

10. Җәмәгатьчелек фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда катнашучылар тәңгәлләштерү (таныклау) максатларында үзләре турында мәгълүматларны (фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта), туган көнен, яшәү (теркәлү) урынын - физик затлар өчен; исеме, төп дәүләт теркәү номеры, урнашу урыны һәм адресы - юридик затлар өчен), мондый мәгълүматларны раслый торган документлар кушып тапшыралар. Тиешле җир кишәрлекләренә һәм (яки) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларына һәм (яки) капиталь төзелеш объектларының күрсәтелгән объектларының бер өлеше булган биналар хокукына ия булган җәмәгатьчелек фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда катнашучылар шулай ук мондый җир кишәрлекләре, капиталь төзелеш объектлары, күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналар турында белешмәләр күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан һәм аларның мондый җир кишәрлекләренә, капиталь төзелеш объектларына, капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарга хокукларын билгели яисә раслый торган башка документлар тапшыралар.

Әлеге маддәнең 12 өлешендә күрсәтелгән җәмәгатьчелек фикер алышуларында катнашучылар турында мәгълүматларны (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), туган көне, яшәү урыны (теркәлү) – физик затлар өчен; исеме, төп дәүләт теркәү номеры, урнашу урыны һәм адресы – юридик затлар өчен) раслаучы документларны тапшыру таләп ителми, әгәр әлеге затлар тарафыннан җәмәгатьчелек фикер алышуларында каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр рәсми сайт яки мәгълүмат

системалары аша кертелсә (бу мәгълүматлар рәсми сайтта яки мәгълүмат системаларында урнаштырылган очракта).

11. Җәмәгатьчелек фикер алышуларында яки ачык тыңлауларда катнашучыларның шәхси мәгълүматларын эшкәртү "Персональ мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып башкарыла.

12. Әлеге маддәнең 10 өлеше нигезендә кертелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җәмәгатьчелек фикер алышулары яки гавами тыңлауларда катнашучы тарафыннан дөрес булмаган белешмәләр бирү факты ачыкланган очракта каралмый.

13. Җәмәгатьчелек фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны оештыручы тарафыннан җәмәгатьчелек фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектка,җәмәгатьчелек фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда катнашучыларның барысына да тигез керү тәэмин ителә (шул исәптән җәмәгатьчелек фикер алышулары уздырганда рәсми сайтка, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә һәм (яисә) Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары биналарында, аларга буйсынучы оешмалар биналарында мәгълүмати системаларга керү мөмкинлеген бирү юлы белән).

14. Рәсми сайт һәм (яки) мәгълүмат системалары түбәндәге мөмкинлекне тәэмин итәргә тиеш:

- җәмәгатьчелек фикер алышуларында катнашучылар тарафыннан рәсми сайтта һәм (яки) алар тарафыннан кертелгән тәкъдимнәрнең һәм искәрмәләрнең мәгълүмати системаларында чагылышның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерүне;
- җәмәгатьчелек фикер алышуларының нәтиҗәләре, җәмәгатьчелек фикер алышуларында катнашучыларның саны турында мәгълүмат бирүне.

15. Җәмәгатьчелек фикер алышуларын яисә ачык тыңлауларны оештыручы җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә ачык тыңлаулар беркетмәсен әзерли һәм рәсмиләштерә, анда күрсәтелә:

- җәмәгатьчелек фикер алышулары һәм ачык тыңлаулар беркетмәсен рәсмиләштерү датасы;
- җәмәгатьчелек фикер алышуларын яки ачык тыңлауларны оештыру турында мәгълүмат;
- җәмәгатьчелек фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда катнашучыларның тәкъдимнәре һәм искәрмәләре кабул ителгән срок турында, аның кысаларында җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар үткәрелә торган территория турында мәгълүмат;
- җәмәгатьчелек фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда катнашучыларның тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен җәмәгатьчелек фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда катнашучы һәм даими яшәүче гражданнарның тәкъдимнәренә һәм кисәтүләренә бүлеп, алар чикләрендә җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар үткәрелә торган

территориядә, һәм җәмәгатьчелек фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда катнашучыларның башка тәкъдимнәре һәм искәрмәләре.

16. Җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар беркетмәсенә җәмәгатьчелек фикер алышуларында катнашучылар яисә гавами тыңлауларда катнашучылар проектын карауда катнашкан җәмәгатьчелек фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда катнашучылар турында мәгълүматларны үз эченә алган исемлек теркәлеп куела (физик затлар өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, яшәү урыны (теркәлү) адресы – физик затлар өчен; исеме, төп дәүләт теркәве номеры, урнашу урыны һәм адресы - юридик затлар өчен).

17. Җәмәгатьчелек фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда каралган проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр керткән иҗтимагый җәмәгатьчелек фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда катнашучы үзе тарафыннан кертелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне үз эченә алган җәмәгатьчелек фикер алышулары беркетмәсеннән өземтә алырга хокуклы.

18. Җәмәгатьчелек фикер алышуларының яисә ачык тыңлауларның беркетмәсе нигезендә җәмәгатьчелек фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны оештыручы җәмәгатьчелек фикер алышуларының яисә ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләүне гамәлгә ашыра.

19. Җәмәгатьчелек фикер алышулары һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәдә күрсәтелергә тиеш:

- җәмәгатьчелек фикер алышулары һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне рәсмиләштерү датасы;
- җәмәгатьчелек фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда каралган проектның исеме, җәмәгатьчелек фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда катнашкан җәмәгатьчелек фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда катнашучылар саны турында мәгълүматлар;
- җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар беркетмәсенең реквизитлары, аның нигезендә җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләнгән;
- җәмәгатьчелек фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда катнашучыларның тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен, җәмәгатьчелек фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда катнашучыларның һәм территориядә даими яшәүче гражданнарның тәкъдимнәренә һәм кисәтүләренә һәм башкаларныкына бүлеп карау;
- берничә җәмәгатьчелек фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан бер үк тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелгән очракта, мондый тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерү рөхсәт ителә;
- җәмәгатьчелек фикер алышуларын оештыручының яисә гавами тыңлауларның катнашучылары тарафыннан кертелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларны исәпкә алуның максатчанлыгы яисә

максатка яраксызлыгы турында дәлилле тәкъдимнәре һәм нәтиҗәләре һәм җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча ясалган нәтиҗәләр.

20. Җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмә муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми рәсми төстә игълан итү өчен билгеләнгән тәртиптә игълан ителергә һәм рәсми сайтта һәм (яисә) мәгълүмат системаларында урнаштырылырга тиеш.

21. РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезләмәләре нигезендә муниципаль берәмлек уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә:

- проектлар буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларын яисә ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе;
- җәмәгатьчелек фикер алышуларын яки ачык тыңлауларны оештыручы;
- җәмәгатьчелек фикер алышуларын һәм ачык тыңлауларны үткәрү вакыты;
- рәсми сайт һәм (яки) мәгълүмат системалары;
- җәмәгатьчелек фикер алышулары яки гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү урнаштырылган мәгълүмат стендларына карата таләпләр;
- җәмәгатьчелек фикер алышуларының яисә гавами тыңлауларның башлануы турында хәбәр итү рәвеше, җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү тәртибе һәм формасы, җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү тәртибе һәм рәвеше;
- җәмәгатьчелек фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен уздыру тәртибе, шулай ук җәмәгатьчелек фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләргә консультация бирү тәртибе”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Шомбыт авылы, Совет урамы, 18 йорт; Шомбыт авылы, Завод урамы, 22 йорт; Шестая Речка авылы, Лесная урамы, 6 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ндаурнаштырырга.

3. Карар, әлеге карарның 4 пункты белән үз көченә керүнең башка вакытлары билгеләнгән нигезләмәләрдән гайре, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге Советының 2019 елның 1 июнендәге 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль

районы “Шомбыт авыл җирлеге”муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренең 26 маддәсенең 8 өлеше 2 абзацына, 26 маддәсенең 8 пунктының 15 абзацына, 27 маддәсенең 5 өлеше 3 пунктына кертелгән үзгәрешләр 2019 елның 1 июленнән үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомбыт авыл җирлеге башлыгы Н.Е.Сергеев